ГЛАВА ТАШКИЧУЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.21А, д.Малые Уруссу, 423959

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАШКИЧҮ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Совет урамы, 21А йорт, Кече Урыссу авылы., 423959

Тел.:(85593) 4-23-10, факс:4-23-40, e-mail: Tash.UTz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 11 14.03.2024 ел

*2023 елның 25 октябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Хөррият торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 1 санлы, 2023 елның 25 октябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Хөррият торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 1/1 санлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Хөррият торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында*

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Уставының 22 маддәсенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Ташкичү авыл җирлеге» муниципаль берәмлек башлыгы

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2024 елның 25 мартында 14 сәгать 00 минутта Татарстан Республикасы, Ютазы муниципаль районы, Хөррият авылы, Хөррият урамы, 5 санлы йорт каршындагы адрес буенча урнашкан бина янында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Хөррият торак пунктында 2023 елның 25 октябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Хөррият торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 2 санлы, 2023 елның 25 октябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Хөррият торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 2/1 санлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез эшләнәсе эшләрне түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 25 октябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Хөррият торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы

2 санлы, 2023 елның 25 октябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлегенең Хөррият торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 2/1 санлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертүгә сез ризамы:

« - Хөррият торак пунктында традицион күмү урыннарын ремонтлау, коймалап алу, төзекләндерү (зират территориясендәге коймалар урнаштыру (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү))»

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең мәгълүмати-стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматларының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru электрон адресы һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталын «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru электрон адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карар аның игълан ителү көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Р.К.Вәлиев